Бүгенге санда:



Нурлатта парклар артачак. 2 бит


# Дуслык
Дружба

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Җомга
10
апрель
2015 ел

№ 26 (10555)


**11 апрельгә һава торышы:** болытлы һава, яңгыр, үзгәрүчән юнәлешле җил 4-6 м/с; температура көндез +6°С, төнлә +4°С

### Җиңү календаре

## 29

**БӨЕК ҖИҢҮ КӨНЕ – 9 МАЙГА КАДӘР ШУЛКАДӘР ВАКЫТ КАЛДЫ**

*1945 елның 10 апреле – сугышның 1389нчы көне. Бүген Халыкара каршы тору көче хәрәкәте көне, ул Икенче бөтендөнья сугышында оккупацияләнгән территорияләрдә фашистларга каршы торучыларга багышлана. Төрле илләрдән хәрәкәттә катнашучыларның гамәлләре гитлерчыларның җиңелүенә һәм сугышның азагына якынлашуына китерде.*

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

*Абзац-информ*

### САВЫМ АППАРАТЫНА – СУБСИДИЯ

Бу көннәрдә районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары 3–8 баш савым сыер асраучы, республика субсидиясеннән файдаланып савым аппараты сатып алырга теләүче шәхси ярдәмче хуҗалыкларны барлау белән мәшгуль. Программа буенча 2015 елда савым аппараты сатып алган ярдәмче хуҗалыкларга аппарат бәясенең 40 процентын субсидияләү күздә тотыла. Республика буенча бу максатларга 20 млн. сум средство бүлеп бирелгән.

### ФЕРМА ТӨЗЕСӘҢ – 200 МЕҢ

Шәхси ярдәмче хуҗалыкларга ярдәм йөзеннән 3–8 сыер асраучыларга республика бюджетыннан сөт юнәлешендәге терлекчелек биналары төзүгә дә 200 мең сумга кадәр субсидия бирү күздә тотыла. Программа республика һәм муниципаль районнарның уртак финанславы шартларында тормышка ашырылачак.

### ТӘРТИПСЕЗЛӘР БАР ӘЛЕ

Атна дәвамында район юлларында ЮХИДИ хезмәткәрләре 9 исерек машина йөртүчене тоткарлаганнар. Штрафларын вакытында түләмәгән 9 транспорт хуҗасына беркетмә төзелгән һәм эшләре судка юлланган. Атна дәвамында барлыгы 8 вак юл-транспорт һәлакәте, юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуның 188 очрагы теркәлгән.

### АУ СЕЗОНЫ АЧЫЛА

Киләсе шимбә, 18 апрельдән районда язгы ау сезоны старт ала. 10 көн дәвамында аучылар киек кошлар аулый алачак. Район аучылары оешмасы бу көннәрдә язгы ау сезонына рөхсәт кәгазьләре бирү белән мәшгуль.

### “ДУСЛЫК”КА ЯЗЫЛУ БАРА

*“ДУСЛЫК” (“ДРУЖБА”, “ТУСЛАХ”) район газетасына 2015 елның II ртыеллыгына язылу бара.*

Сезне почтада һәм редакциянең реклама бүлегендә көтәләр.

# Бизнесны сакларга традицияләр булыша



Лилия Мөбарәкшина фотосы

ИРИНА МУСИНА ҺӘМ ВЕРА КУЛЬМЕТЬЕВА СӨТ ФАСОВКАЛАУДА

“Нурлат сөте”нең сөт заводында гадәти эш көне. Бер почмакта сөт фасовкалау бара, икенче якта хезмәткәрләр май төргәкләргә җыена, шунда ук эремчек әзер булып килә. Әле тагын пастеризацияләү ванналарында кефир, ряженка, катык кебек ризыклары өлгереп килә... 2004нче елда эшчәнлеген зур булмаган җитештерү күләменнән башлап җибәргән сөт заводында хәзер 10 исемдәге 12 төр сөт продукциясе җитештерелә. Республика Президенты вазифаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миннеханов муниципалитетлар алдына эшмәкәрлекне актив һәм уңышлы үстерү бурычы куйды бит. Бурычын гына куймый, төрле программалар белән ярдәмен дә күрсәтә республика җитәкчелеге. Шуңа да бүгенге көндә предприятие җитәкчелеге продукция җитештерүне киңәйтүгә аеруча игътибар бирә.

- Моннан 11 ел элек эшне сөт, каймак һәм май ясаудан башлаган идек, - ди директор урынбасары Тәлгать Гилялов. – Хәзер исә завод – 41 кешегә эш урыны биргән тотрыклы предприятие.

Ул чагында әле районның озак еллар эшләп килгән сөт-май заводының да гамәлдә чагы, көндәшлек шартларында производствоны үстерү, ассортиментны киңәйтү өстендә эшләргә туры килә. Сүз дә юк, сөт бизнесы җиңеллләрдән түгел – продукциянең сыйфатына карата таләпләр кырыс, өстәвенә, завод ачылганда ук җәмгыятьнең учредителе Шамил Яһудин бары тик натураль ризыклар гына җитештерергә дигән бурыч куя. Ә “натураль” иң беренче чиратта кыйммәтле дигән сүз. Һәм коллективка халыкка кулай бәяләрдән натураль продукция тәкъдим итү өчен алтын урталыкны табып эшләргә туры килә. Һәм бу үзен аклый да – илдәге кайбер эре сөт җитештерүчеләр дә банкротлыкка чыккан кризислы елларны да “Нурлат сөте” ышанычлы кичерә. Монысына, әлбәттә, заводка чималның турыдан-туры үз хуҗалыкларыннан килүе дә ныклы ярдәм булгандыр.

*(Ахыры 3нче биттә)*

*“Татарстанда кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү чаралары” – бу турыда тулырак мәгълүмат “Атна вакыйгалары”нда*

ЯЗГЫ ТАШУ

# Су күтәрелә башлады

**Елгаларда су күтәрелә башлады. Мисал өчен, кичәгеге көнгә Тәрнәстәге Зур Сөлчә елгасында су 45 сантиметрга күтәрелгән.**

– Елга ярларыннан чыкмады, - ди Тәрнәс авыл җирлеге башлыгы Сергей Белов. – Күзәтүләрне тәүлегенә 2 тапкыр алып барабыз, күрсәткечләрне билгелибез, тәүлек әйләнәсе кизү оештырылды. Бары тик елгада су 2 метрга кадәр күтәрелә калса гына җирлектәге 23 йортка су басу куркынычы яный. Шөкер, соңгы елларда андый хәлнең булганы юк. Узган ел бу вакытта су 30 сантиметрга кадәр күтәрелгән булса, максималь күтәрелеш 1 метр да 30 сантиметр тәшкил итте.

125нче янгын частенең кизү бүлеге хәбәренчә, Мамыктагы Зур Сөлчәдә су – 25, Киекле һәм Заречный торак пунктларындагы Зур Чирмешәндә – 25, Яңа Иглайдагы Кондырчада – 20гә, Богдашкинодагы Киклинкада – 10, Кычытканлының Мораса елгасында бары 5 сантиметрга күтәрелгән.

Нурлат янгын сагы гарнизоны начальнигы Илһам Курамшин әйтүенчә, ситуация контрольдә, су басу куркынычы юк.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

# ВӘЗГЫЯТЬ

ШӘҺӘР

## Сәүдә баргач, штраф куркыта димени?!

**Чәршәмбе көнне административ комиссия үз утырышында 17 беркетмә карады.**

Комиссиягә беркетмәләр төрле ведомстволардан керә: шәһәр прокуратурасыннан, полициядән, экологик службадан да. Каралган материаллар арасында төзекләндерү кагыйдәләрен бозу, тиешле булмаган урында сәүдә итү, шулай ук муниципаль-хокукый актларны үтәмәү кебекләр бар иде. Бу көнне шәһәр прокуратурасыннан административ хокук бозу кодексын санга сукмауга кагылышлы беркетмә керде – предприятие җитәкчелеге хезмәткәрләрен эштән чыгаргач, вакантлы урыннар булуы турында мәшгульлек үзәгенә хәбәр итмәгән. Җитәкчегә 15000 сум штраф салынды. Шулай ук төзекләндерү кагыйдәләрен бозу турындагы беркетмәләр буенча да штрафлар билгеләнде. Мисал өчен, административ хокук бозу турында беркетмә төзергә вәкаләте булган район башкарма комитеты территориаль үсеш бүлеге белгече 2 апрельдә Ишкинеев урамында яшәүче берәүгә беркетмә төзи. Административ комиссиягә күрсәтелгән шул ук көнне төшерелгән фоторәсемдә төзелеш материаллары өеме тасвирланган. Хуҗалар исә комиссия әгъзаларын аны "чәчәклек" дип ышандырырга тырыштылар. Болай фикер йөртсәң, шәһәребезнең шәхси секторындагы урамнар "чәчәклеккә" күмелгән булып чыга түгелме соң?

– Ни өчен башкаларга штраф салмыйсыз? – дип комиссия әгъзаларына соравын җиткерде әлеге кыз.

– Төзелеш материалын җыеп тотарга шәһәр башкарма комитетыннан рөхсәтләре булмаганнарның барысына да штраф салына, – дип җавап бирде аңа административ комиссия рәисе урынбасары Лилия Закирова. – Тирә-яктагы территорияне төзекләндерү стандартлары бар, ә бу очракта бер өем елга ташы һич тә чәчәклек була алмый.

Утырышка тиешле булмаган урында сәүдә итүчеләр дә чакырылган иде. Мәсәлән, балык сатучы шәхси эшмәкәрләргә беркетмәне полиция хезмәткәре төзегән. Балыкны урамда гына түгел, ә юл читендә, җирдән үк сатучы эшмәкәргә полициянең генә түгел, санитар службаларның да сораулары булуы ихтимал. Комиссия әгъзалары мондый утырышларда үкенү һәм алга таба болай булмас, дигән ышандыруларны еш ишетәләр. Бу очрак та искәрмә булмады. Тик минә ышанырга кирәкме икән, чөнки әлеге эшмәкәргә тиешле булмаган урында сату иткәне өчен беркетмәне беренче тапкыр гына төзүләре түгел икән инде. Күрәсең, аңа әлегә кагыйдә бозмыйча эшләүгә караганда, штраф түләве отышлырактыр. Югыйсә, штраф суммасы да яңгыраган утырыштан кайтуга ук эшмәкәр янә элеккеге урынына ук балыклы тартмаларын тезеп куймас иде...

Сирень СӘМӘРХАНОВА




БАЛЫКЛЫ ТАРТМАЛАР ӘЛЕ ДӘ УРЫНЫНДА




## Базар үзгәреш көтә

**Базар янындагы юл бoҗрасы һәм Гагарин урамының 26нчы йорт ишегалдындагы парковка мәсьәләсе хәл ителер, ахрысы. "Юниор" универсаль базары җитәкчелеге әлеге проблеманы вак сәүдәгәрләрнең ("челночник") сату урыннарын күчереп чишәргә булган.**

– Хәзер базардагы барлык сатучылар да бер урында булачак, - ди базар җитәкчесе Айрат Вәлиуллин. – Базарның кием-салым сата торган ягындагы буш рәтләргә яшелчә, үсентеләр, орлыклар, чеби-тавыклар сатучыларны күчердек. Бу чисталык проблемасын да хәл итәр дип өметләнәм. Моңа кадәр вак сатучылар чүп-чарны теләсә кая ташлап калдыралар иде. Ә бит монда социаль мөһим объектлар урнашкан. Мәчет, хастаханәгә йөрүче халыкның күбесе шушы чүп-чар аша уза иде. Аннан базарны берләштерүнең тагын бер уңай ягы – парковка булу. Базарга элеккеге ДРСУ ягыннан кергәндә, транспорт хуҗалары үзләренең машиналарын махсус стоянкада калдыра ала.

Базардагы үзгәрешләрнең плюсларын вак сәүдәгәрләр үзләре дә тоярга өлгергән инде.

– Моңа кадәр урын өчен көн саен түләсәк, хәзер түләүләр аена бер тапкыр гына булачак, - диләр сатучылар.

ЮХИДИ инспекторлары әлеге үзгәрешләр юлларда тәртип салырга ярдәм итәр, дип өметләнә.

– Шәһәрдәге проблемалы участокларның берсе – базар янындагы юл боҗрасы, - ди ЮХИДИнең өлкән дәүләт инспекторы Петр Фадеев. – Бирелдәге теләсә ничек куеп калдырылган автотранспортлар юл хәрәкәтенә комачау итеп кенә калмыйча, еш кына һәлакәтләр дә китереп чыгара иде бит. Әлеге хәбәргә иң сөенгәне Гагарин урамы 26нчы йортында яшәүчеләр булырдыр, мөгаен.

Зилия ӘКСАНОВА

## Бизнесны сакларга традицияләр булыша

*(Ахыры. Башы 1нче биттә)*

Район җитәкчелеге дә җирле дәрәҗәдә урта һәм кече эшмәкәрлекне үстерүгә йөз тотып эшли. Әнә, күптән түгел район башлыгы Равил Кузюров та сөт заводына чираттагы визиты барышында җитештерү күләмен арттыру, моның өчен җирле эшмәкәрләрне күбрәк үзебез завод белән эшләргә җәлеп итү бурычы куйган иде. Шуны истә тотып, завод сөт җыючылар белән эшләү өчен яңа шартлар булдырып, бүгенге көндә 25 тоннага кадәр чимал кабул итә, шуның 15 тоннасын эшкәртә. Шул көннәрдә яңа пар генераторын урнаштырулары да җитештерүнең яңа этабына чыгарга һәм продукциянең үзкыйммәтенә уңай тәэсир итәргә тиеш. Бусы да халык файдасына булачак. Дистә елдан артыграк үз традицияләренә тугры калып килгән коллектив алга таба да шул юлдан борылырга җыенмый. Уңышлы бизнесның нигезен исә әнә шулай иң беренче чиратта тотрыклылык тәшкил итә дә.

Лилия МӨБӘРӘКШИНА

**"Нурлат сөте"** *продукциясе: сөт, эремчек, май, кефир, катык, снежок, ряженка, каймак, ацидофиллы эчемлек – бары натураль компонентлардан җитештерелгән файдалы ризыклар.*
*"Нурлат сөте" продукциясен сайлагыз һәм сәламәт булыгыз!*
*Түмәрләп алучылар өчен* тел: **9–01–35.**




ӨЧ КАДР



### ЮЛЛАР РЕМОНТЛАНА

НУАД юлчылары чокыр ремонтын дәвам итә. Бу сезонда алар Ленинград һәм Самаренкин урамнарындагы төбәк багланышындагы 200 кв.метр юлны ремонтлаганнар.

- Чокыр ремонтын шулай ук Чистай – Аксубай-Нурлат һәм Кузайкино – Нурлат автоюлының 3100 кв.метрында ясадык, – ди идарәнең ПТО инженеры Рәмис Абдуллин. – Ремонт дәвам итә. Бу көннәрдә предприятие юлчылары Нурлат –Чуваш Тимерлеге автоюлында эшли.

ӨЧ КАДР



### ЯШЬЛӘР СӘЛАМӘТЛЕК ЯКЛЫ

Бөтендөнья сәламәтлек көне кысаларында шәһәрдә "Наркотикларга юк!" акциясе узды. "Акциябезнең максаты – җәмгыятьнең, аеруча яшьләрнең игътибарын наркомания проблемасына тарту", – ди 8нче мәктәп укытучысы, "Мөстәкыйль балалар" проекты җитәкчесе Роза Сафина. Акциядә 8нче мәктәпнең 54 укучысы катнашты. Алар бер сәгать эчендә шәһәрлеләрдән имза җыю буенча конкурста да катнаштылар. Иң күп имза җыючы укучы Анастасия Васильева "Костер" сәламәтләндерү лагерена юллама белән бүләкләнде. Акциягә 2нче мәктәп укучылары да кушылды.

ӨЧ КАДР



### КОШЛАРГА – УҢАЙЛЫ "ФАТИРЛАР"

Кояш җылысы төшә һәм карлар эри башлау белән җылы яклардан сыерчыклар кайта. Төньяк микрорайонындагы бер йорт хуҗалары яз хәбәрчеләрен каршы алырга ныклап әзерләнгәннәр. Үз йортларының фронтонына алар өч сыерчык оясы элеп куйганнар. Ояларның һәрберсе төрле ачык төсләргә дә буялган, алар әллә кайдан күренеп тора. Бу оялар кошларның берничә буынына туган нигез булыр әле. Ә хуҗалар һәм тирә-күршеләр иртә-кичләрен кош сайрауларын тыңлап хозурланырлар.

АВЫЛ

# Йөзгә кадәр яшисең килсә... кәҗә сөте эч!

**Татарстанда кәҗә асраучыларга да дәүләт ярдәме күрсәтмәкчеләр. Әлегә бер кәҗәгә күпме акча тиясе билгеле булмаса да, кәҗә асраучылар бу яңалыкны хуплап каршы алган. Чөнки моңа кадәр субсидияләр баш санынnan чыгып бары тик савым сыер асраучыларга гына бирелә иде бит. Димәк, кәҗә мал түгел, дип санаучыларның саны кимиячәк.**

Хәер, Егоркино авылында кәҗә күптәннән инде "авторитетлы" маллардан санала. Бүгенге көндә авыл җирлегендә 140 баш кәҗә исәпләнүен генә күр син. Шуларның 75е – савым кәҗә.

- Авыл халкы нигездә Нурлатка йөреп эшли. Шуңа да сыер асрауны мәшәкатьлегә санап, көндәлек ихтыяҗларга дип кәҗә асрауны хуп күрәләр, - дип аңлата моны авыл җирлеге башлыгы Валентина Яковлева.

Иң күп кәҗә исә Ендиряковлар хуҗалыгында - 7 баш кәҗәләре, тагын 19 кәҗә бәтиләре бар бүгенге көндә. Моннан 7 ел элек сыер асраудан туктагач, өлкән яшьтәге әбиләренә сөте файдалы дип бер кәҗә сатып алган гаиләдә баш саны елдан-ел ишәя бара. Кәҗәләрне исә ниндидер бер үзгә ярату белән асраулары күренеп тора. Әнә, хуҗабикә Альбина Ендирякова иртәннән кулына ике чиләген алып кәҗә саварга ашыга. Кәҗә бәтиләрен хуҗа Юрий Леонидович инде утарга чыгарган, йөгерешә-йөгерешә печән, үзләренә дип җәйдән махсус әзерләнгән киптерелгән агач ботакларын кимерүләрен беләләр. Ә эчке якта савым кәҗәләр хуҗабикә күренү белән ишек янына тезелешә. Альбина Петровна гадәттәгечә иң беренче итеп иң өлкән кәҗәне савымга алып чыкты. Янәшәдә генә кәҗә саву өчен аерым урыннары бар икән, кәҗә чыгу белән шунда менеп басты да, акрын гына яшел печән уртларга кереште. Берничә минут... Һәм менә хуҗабикә инде яңа савылган парлы сөтне банкага агыза – 2 литрга якын. Шунда ук авыз итеп тә карыйбыз – сыер сөтеннән берни белән дә аерылмый, тәмлерәк тә бугай әле.

- Әле тагын кичен ике литрлап сөт савам. Майлылыгын үлчәтеп караганыбыз бар, 8,5 процентттан да ким булмый. Сөттән сыр да әзерлим, аертып каймагын да ясыйбыз, катыгы да үзебезнеке, шикәр дә кайнатам, - дип сүзен дәвам итә хуҗабикә. – Артканын сатабыз да. Авыл халкы гына түгел, шәһәрләләр арасында да үз клиентларыбыз бар. Сабыйлар өчен алучылар да, төрле авырулардан файдасын табучылар да шактый. Аннан, кәҗә сөтендә файдалы матдәләр бик озак саклана бит. Өй шартларында да өчәр көн әчеми, ә суыткычта атна буена свежий тора.

Кәҗәләрне саву, сөттән ризыклар әзерләү әнә шулай Альбина Петровнаның вазифасы булса, ашату, тәрбияләү күбрәк Юрий Леонидович өстендә.

- Костер, люцернаны яратып ашыйлар, рационда солы, арпа, катнаш азык та бар. Акбур, тоз кебек өстәмәләр дә бирәбез, әле тагын кызыл чөгендерне бик яратып ашыйлар, - ди ул. – Суның исә җылытып кына бирергә кирәк.

Бусы - кышын. Ә менә җәен кәҗәләр көне буена табигать нигъмәтләре – яшел үләннәр белән туклана. "Күршең белән талашасың килсә, кәҗә асра" дигән халык әйтеме исә Ендиряковларга һич тә туры килми. Чөнки өйләре авыл читендә генә, бакча башында ук яшел үләнле болыннар җәйрәп ята. Савым кәҗәләрне шунда бәйләп куялар, ә бәтиләре әниләре яныннан китми диярлек, өй янына бары су эчәргә генә кайтып китәләр икән.

- Кайчак кичен алып кайтырга вакыт булмый торганда, әллә ничә тапкыр кайтып әйләнәләр, кибеттә булсам, анда да килеп җитәләр, - дип сүзен дәвам итә Альбина Петровна. Хуҗабикә өйдәге вак-төяк мәшәкатьләр белән бергә көн дәвамында йортлары янында гына урнашкан үз кибетләрендә сату итәргә дә өлгерә әле. Моннан тыш, 49 сутыйлы галәмәт зур бакчалары, теплицалары да бар. Бакчада алмагачлары гына да кайчандыр 50 төпкә якын булган, кыяр-помидорны да җәй башыннан күпләп үстерәләр, үзләреннән артканын сатып та керем алалар икән әле.

Кәҗәләрнең ниндидер аерым токымлыларын үрчетүне максат итми Ендиряковлар. Үзләре әйтүенчә, сакалбайларның гади, халык арасында да тау токымлы дип йөртелә торганнары аларда. Шуңа да, мөгаен, биеклеккә менәргә яраталар. Әнә, кәҗә бәтиләре хуҗаның өй салырга дип әзерләп куйган төзелеш материаллары өстендә йөгерешәләр генә.

- Хәтта түбәгә кадәр менеп киткән чаклары була. 5 метрлы биеклек аша сикереп чыгарга мөмкиннәр, - диләр хуҗалар.

Алга таба кәҗәләрнең санын арттырырга дигән ниятләре дә юк түгел. Кәҗә фермасы ачуга да каршы түгелләр. Татарстанда уңышлы гына эшләп килүче кәҗә фермалары турында ишетеп торалар, ләбаса. Өстәвенә, ферма ачып, кәҗә асрау белән ныклап шөгыльләнергә теләүчеләргә дәүләттән төзелеш, терлек, җиһазлар сатып алу өчен субсидияләр дә каралган. Аннан, кәҗә асрауның өстенлекле яклары да күрергә өлгергәннәр инде – әлләни зур чыгымнар сорамый, ә продукциясе шактый кыйммәт – кәҗә сөтенең бер литры 120 сум тора бүгенге көндә.

Ә авыл җирлеге башлыгы Валентина Яковлева эшләр болай артуга таба барса, авылда кәҗә көтүе оештырырга да туры килмәгәе, дип планнар кора. Чит илдән кертелгәнен көтеп ятканчы, продукцияне үзеңдә җитештерү күпкә файдалырак бит – керем дә килеп тора, сыйфаты өчен дә борчыласы түгел. Аннан Гиппократ та юкка гына : "Кәҗә сөте эчсәгез, 100гә кадәр яшәрсез!" дип әйтеп калдырмаган бит.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**




**МӘГЪЛҮМАТ**

*× Районда 1168 баш кәҗә исәпләнә, шуларның 663е – савым кәҗә.*

*×1906 елда Парижда үткән балалар табибларының Бөтендөнья конгрессында кәҗә сөте ана сөтен алмаштыручы иң яхшы табигый продукт итеп табылган.*

*× Кеше организмы кәҗә сөтен сыер сөтенә караганда 5 тапкыр җиңелрәк үзләштерә.*

*× Кәҗә сөте организмнан радионукледларны чыгарырга сәләтле. Аның составында иммуноглобулин бар, һәм ул төрле авыруларны, хәтта туберкулезны дәвалау һәм профилактикалау өчен дә кулланыла.*

ЭКОЛОГИЯ

# "Чүп патшасын" куып җибәрделәр

**Сер түгел, балалар тирәяктагы күренешләрне үзләренә йоктыра. Тәртипкә, чисталык булдырырга өйрәтү – районның баш экологы үзалдына әнә шундый бурыч куйган.**

Бу хакта сөйләшүне Нурлат районында табигатьне саклау инспекторы Рөстәм Ногманов 2нче мәктәпнең III сыйныфы укучылары белән үткәрде.

– Кече сыйныфлар өчен экологик темага лекцияләр кызыклы түгел, – дип саный ул. – Шуңа да бу проектны балалар өчен аңлату клубы дип атарга була, ул аралашуга корылган. 8, 9, 10нчы сыйныф укучылары белән бергәләп без театрлаштырылган тамаша әзерләдек.

Мисал өчен, тамашада дус-ишләре белән Чүп патшасы да бар иде. Аларны ерактан ук таныдылар – киемнәренә пластик шешәләр, сок пакетлары, кәнфит кәгазьләре, – кыскасы, еш кына чүп савыты урынына юлга, тротуарга ташланылучы нәрсәләр беркетеп чыкканар иде алар. Чүп патшасы балаларга төрле киртәләр тудырса да, нәни укучылар экологик тәртип бозучыны җиңә алдылар. Чүп патшасын да, аның дус-ишләрен дә куып җибәрделәр: моның өчен укучыларга табышмаклар, ребуслар чишәргә, конкурсларда катнашырга туры килде. Ә соңыннан "Яшь Гвардия" иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Ленар Әһлиуллин нәни тамашачылар өчен "Ни өчен чүпләргә ярамый?" дигән тренинг үткәрде. Бер укучы чүпләр ташласа, икенчесе аларны җыйды, аннан алышынып уйнадылар. Соңыннан барысы да тәэсирләрен уртаклаштылар. Баксаң, беркемгә дә икенче берәү артыннан чүп җыеп йөрү ошамый икән. Кече яшьтәге укучылар өчен аралашуның мондый формасы кызыклы гына түгел, файдалы да иде. Шуңа да, Рөстәм Ногманов киләсе атнада бу тамашаны башка мәктәпләрнең укучыларына да тәкъдим итәбез, диде.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**




БАЛАЛАРГА ЭКОЛОГИЯ ПРОБЛЕМАЛАРЫ ТЕАТРЛАШТЫРЫЛГАН ТАМАША АША ҖИТКЕРЕЛДЕ

# КОТЛАУЛАР. БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА

*Газета расширяет возможности для своих читателей. Теперь вы можете поздравить своих родных и близких в сети Интернет (на сайте газеты www.nurlat-tat.ru и Вконтакте) всего за 100 рублей. Подробности по тел. 2-36-12.*

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Биккол авылында яшәүче кадерле тормыш иптәшем, әтиебез **Әсхәт Зәки улы Минегуловны** 55 яшьлек юбилее белән чын күңелдән котлыйбыз!

Сиңа аяз күк йөзе, ак бәхетләр, нык сәламәтлек, озын гомер, чиксез шатлыклар телибез. Сабыр холыклы, мәрхәмәтле, ярдәмчел, кадерледән кадерле син. Киләчәктә дә киң күңелле, ачык йөзле, олы йөрәкле булып кал.

55 ел узып киткән  
Сизми-сизелми генә,  
Тормыш юлын синең кебек  
Матур үтәр кем генә...  
Син бит безнең өчен кояш,  
Синнән нурлар алып яшибез,  
Озак яшә, мәңге картайма,  
Иң кадерле, якын кешебез.

**Чиксез хөрмәт, мәхәббәт белән тормыш иптәшең, балаларың.**

Хөрмәтле гаилә дустыбыз **Галидияр Мостафа улы Моратхановны** 60 яшьлек юбилее белән ихлас күңелдән котлыйбыз.

Дөньяның барлык матурлыгын, сәламәтлекнең корычтаен, гомереңнең пар канатлы, озын-озак булуын телибез.

Дөнья тыныч, илләр имин,  
Тормышыңда булсын бәрәкәт,  
Олы җаның, изге күңелең өчен  
Барыбыздан сиңа мең рәхмәт.

**Яруллиннар, Гайнетдиновлар, Низамовлар.**

Кизләү авылында яшәүче кодабыз **Рәис Рәшит улы Гыймалетдиновны** 50 яшьлек юбилее белән тәбрик итәбез!

Туган көнең – юбилееӊ белән  
Чын күңелдән сине котлыйбыз,  
Сәламәтлек, шатлык-  
куанычлар,  
Күңел тынычлыгы телибез.  
Гел шатланып яшә, хәсрәт  
күрмә,  
Тыныч булсын һәрчак күңелең,  
Бәрәкәтле, матур тормыш сиңа,  
Кояшларга тиңә гомернең.

**Иң изге теләкләр белән Әхмәтвәлиевлар гаиләсе.**

Коллегабыз **Рәис Рәшит улы Гыймалетдиновны** 50 яшьлек юбилее белән ихлас күңелдән тәбриклибез.

Олы юбилеегыз котлы булсын!  
Саулык, шатлык, бәхет  
мәңге булсын,  
Уңыш өсләренә уңыш өстәп,  
Муллык өегезгә килеп торсын.  
Балалардан игелекләр килсен,  
Дуслырыгыз сезгә  
тугры калсын,  
Ел артыннан еллар  
гөрләп узсын,  
Олы юбилеегыз котлы булсын!

**Изге теләкләр белән Кизләү мәктәбе укытучылары.**

**Чулпан авылында** гомер кичерүче киленем **Фәзилә Галимҗанованың** 11 апрельдә гомер бәйрәме – юбилее.

Фәзилә! Сиңа гомернең озынын, саулыкның ныгын, тормышның иң матурын телибез.

Җырлыйм дисәң, җырың бар,  
Сөйлим дисәң, сүзең бар.  
Үз көчеңә таянып  
Эшләү өчен эшең бар.  
Исәнлегең мулдан булсын,  
Бәхетең ташып торсын,  
Ислам улым белән тигезлектә  
Яшәргә насыйп булсын.

**Иң изге теләкләр белән Әлфия, Миннегөл, Солтан гаиләләре исеменнән каенанаң Мәрьям.**

## КҮЧЕМСЕЗ МИЛЕК

*Төзелеп бетмәгән йорт, Көньяк-көнбатыш мкр., Сембер ур.,17. Т. 8-927-466-21-44.

*4 фатирлы йортта 3 бүлмәле фатир. Т. 8-927-474-46-16.

*2-комнатная квартира, ул. Ленинградская, 9, 1400 тыс.руб. Т. 8-937-003-36-39.

*дом. Варианты. Т. 8-937-283-86-00.

*киоск без места. Т. 8-937-995-21-34.

*дом жилой. Т. 8-927-462-17-01.

*капитальный гараж с дачным участком. Т.: 8-927-871-55-07, 8-927-401-01-89.

*дом или обмен. Т. 8-919-684-40-03.

*дом в с. Тюрнясево. Т. 8-927-435-12-10.

*1-комнатная малосемейка, мкр. Яшлек, большая сторона. Т.: 8-927-415-08-08, 8-960-038-55-73.

*двухуровневый двухквартирный дом (ветлечебница) на участке 13 соток. Т. 8-927-421-12-38.

*1-комнатная квартира, ул. Циолковского, с инд.отоплением, 32 кв.м, 3/5. Торг. Т. 8-927-045-54-68.

*1-комнатная квартира, ул. Советская, 189. Т. 8-927-483-51-85.

*дом в д. Зузеево. Т. 8-919-687-02-79.

*2-комнатная квартира, центр, ремонт, индивидуальное отопление. Т. 8-927-247-86-43.

*новый дом без отделки, ул. Рябиновая. Т. 8-927-406-17-05.

*дом, с. Шламка. Т. 8-927-406-75-70.

*гараж (школа №4). Т. 8-927-450-82-22.

*квартиры, нежилые помещения, коммерческая недвижимость, дома. Т. 8-929-727-12-82, Ксения.

*2-комнатная квартира, с/з, 1 этаж, 750000 руб. Т. 8-937-610-48-70.

*коттедж, центр, 120 кв.м, 3,8 млн. руб. Т. 8-937-610-48-70.

*коттедж, ул. Фахрутдинова, 6,7 млн. руб. Т. 8-937-610-48-70.

*коттедж, с. Тюрнясево, 180 кв.м, новый, 2,8 млн. руб. Т. 8-937-610-48-70.

*жилой дом, ул. Курмышская, 1850000 руб., 100 кв.м. Т. 8-937-610-48-70.

*жилой дом, ул. Тельмана, 90 кв.м, 2,5 млн. руб. Т. 8-937-610-48-70.

*жилой дом, ул. Симбирская, 120 кв.м, 2,5 млн. руб. Т. 8-937-610-48-70.

*жилой новый дом, д. Бурметьево, 700000 руб. Т. 8-937-610-48-70.

*жилой дом, с. Егоркино, 550000 руб. Т. 8-937-610-48-70.

*новая 2-комнатная квартира, 2 этаж, 1350000 руб., 50 кв.м. Т. 8-937-610-48-70.

*3-комнатная квартира, мкр. Яшлек, 5 этаж, 1250000 руб., 60 кв.м. Т. 8-937-610-48-70.

*3-комнатная квартира, с/з, 1 этаж, 70 кв.м, 1 млн. руб. Т. 8-937-610-48-70.

*нежилое помещение, мкр. Нижний Нурлат, 200 кв.м, 1 млн. руб. Т. 8-937-610-48-70.

*2-комнатная квартира, ул. Садовая, 5 этаж, 50 кв.м, или обменивается на 1-комнатную квартиру. Т. 8-937-610-48-70.

*1-комнатная малосемейка. Т. 8-937-280-97-98.

*капитальный гараж, пер. Заводской. Т. 8-927-445-00-14.

## АВТОТРАНСПОРТ

*«ВАЗ-2107», 2007 г/в, один хозяин. Т. 8-927-671-49-88.

*«МАЗ-Самосвал», 2012 г/в, 20 тонн, двигатель Евро-2. Т. 8-9872-86-70-01.

*«ВАЗ-2115», 2008 г/в. Т. 8-937-003-89-86.

*„Лада приора", 2013 г.в., белого цвета. Т. 8-927-406-73-21.

*«ВАЗ-2107», 2007 г/в, пробег 40000. Т. 8-927-045-54-68.

*«ГАЗель», фургон. Т. 8-929-723-06-80.

*«КамАЗ-55111», самосвал, 1992 г/в. Т. 8-927-675-63-85.

*«ВАЗ-2106». Т. 8-927-671-54-48.

*«ВАЗ-2110», 1997 г/в, не гнилая, недорого. Т. 8-927-246-85-25.

## БАШКАЛАР

*ШИКӘР КОМЫ-2250, ОН-970, «Юмарт» кибете. Т. 8-927-445-68-55.

*Ком, ПГС, елга ташы, вак таш. Т. 8-927-244-11-33.

*Костер, люцерна орлыклары. Т. 8-927-470-39-02.

*ПГС, ком. Т. 8-927-424-02-83.

*ПГС, песок, кольца разного диаметра. Т. 8-937-28-62-082.

*ПГС, песок, буткамень. Т. 8-927-247-47-17.

*ПГС, песок, буткамень. Т. 8-927-247-27-37.

*оптом огурцы свежие, тепличные, местные из Нурлатского района. Т. 8-927-679-54-19.

*пшеница. Доставка. Т. 8-937-776-33-35.

*керамзит-керамблоки. Доставка. Т. 8-927-247-85-89.

*пчелосемьи. Т. 8-937-770-46-59.

*песок, ПГС по 15 т. Т. 8-927-405-76-08.

*дрова. Т. 8-937-003-27-27.

*куры-молодки, стационарная печь-дизель. Т.: 4-35-11, 8-927-422-92-58.

*плиты перекрытия, блоки фундаментные, цемент. Т. 8-960-822-72-75.

*б/у кирпич, блоки, плиты, перемычки. Т. 8-9274-222-666.

*ПГС, дрова колотые. Т. 8-937-617-11-21.

*огнеупорный кирпич, б/у. Т. 8-987-287-14-76.

***доски (осина, сосна), брусья. Доставка. Т. 8-937-003-84-85.**

*спальный гарнитур, монитор, системный блок, б/у. Т. 8-927-443-07-45.

*пчелосемьи на высадку, печь на отработке, печь на газу, ворота гаражные. Т. 8-919-685-93-14.

*б/у мягкая мебель (9000), телевизор «Панасоник» (3000), стол-тумба (1500), палас (1500). Т. 8-927-037-48-98.

*сено, солома, телята мясной симментальской породы, недорого. Доставка бесплатно. Т.: 8-960-396-77-71, 8-937-343-80-22.

*2-х спальная кровать, в отличном состоянии, недорого. Т. 8-987-404-28-58.

*пчелы с ульями. Т.: 8-927-427-79-70, 8-927-409-76-18.

*диван. Т. 8-927-430-49-34.

*холодильник. Т. 8-927-676-54-92.

*песок, ПГС. Т. 8-937-283-70-69.

*стенка, дешево. Т. 2-73-89, после 18.00.

**КАМЫШЛЫ ИНКУБАТОРЫ тәүлеклек бройлерларга заявкалар кабул итә. 8-937-620-80-30 (Румия), 4-35-47 (өй).**

*ООО «Спецэнергомонтаж» реализует керамзитобетонные блоки по приемлемым ценам. Обращаться: пер. Заводской, 1а (ЖБИ). Т.: 2-60-75, 2-50-90.

*тракторный прицеп, одноосный. Т. 8-927-419-57-81.

*баня (3х5) с перерубом, низ – дуб, без углов. Т. 8-927-419-57-81.

*двигатель на классику, карбюратор. Т. 8-927-454-11-85.

*двухспальная кровать, летняя резина «Джити Комфорт», R-15 + диски. Т. 8-937-593-08-66.

*коза дойная. Т. 8-927-679-57-13.

## ТӨРЛЕСЕННӘН

*Йомшак җиһаз тарттыру, ремонтлау. Т. 8-937-570-60-21.

*Йөк күчерү, «ГАЗель». Т. 8-937-570-60-21.

*Жалюзиның барлык төрләре, тиз. Т. 8-927-672-01-17.

*Электр монтажлау эшләре. Т. 8-937-614-70-15.

*Электрик хезмәтләре. Т. 8-987-418-35-00.

*Электр монтажлау эшләре. Т. 8-929-728-93-36.

*натяжные потолки. Т. 8-9270-365-365, Алексей.

*грузоперевозки, «ГАЗель». Т. 8-987-413-96-70.

*ремонт квартир. Т. 8-927-419-71-51.

*ремонт холодильников. Т. 8-927-419-56-48.

*сварочные работы (электро-полуавтомат), ремонт АВТО. Т. 8-937-004-40-78.

*грузоперевозки, «ГАЗель», 4 м, 15 куб. Т. 8-927-247-12-61.

*котята. Т. 8-937-527-41-90.

*копаем и чистим колодцы, вручную. Т.: 8-929-723-88-60, 8-986-711-25-30.

*копаем, чистим колодцы. Т. 8-927-481-51-72.

*домашний электрик. Т. 8-917-936-20-96.

*помощь компьютеру. Т.8-909-308-22-56

*строительные работы (бригада). Т. 8-927-400-43-88.

*ремонт холодильников. Т. 8-927-247-93-50.

*ремонт ст.машин. Т.: 8-927-468-16-31, 8-917-926-34-78.

*г/п. Т. 8-927-401-11-76.

*натяжные потолки. Т. 8-927-413-37-58, Иван.

*ремонт, настройка компьютеров, Wi-Fi, Интернета. Т. 8-937-0051-451.

*ремонт холодильников. Т.: 8-937-610-58-78, 2-71-69.

***грузоперевозки «ГАЗель», 4,20, тент. Т. 8-927-442-38-10.**

*услуги погрузчика, "КамАЗа". Т. 8-927-404-92-21.

*кухни и шкафы-купе на заказ, недорого. Т. 8-927-241-26-41.

## БИРЕП ТОРЫЛА

*Тәүлекләп яки сәгатьләп фатир, командировкадагыларга Т. 8-927-456-05-69.

*в аренду магазин 278,8 кв.м по ул. Советская, д. 183А (возле д/с «Сказка»). Обращаться по телефону: 8-917-251-93-15.

*помещение под общепит, магазин, склад, офисы. Т. 8-927-247-40-47.

*2-комнатная квартира, мкр. Яшлек. Т. 8-927-044-00-19.

## КИРӘК

*парикмахер, маникюрист. Т. 8-927-421-80-33.

*водители на хлебовозку, лаборант. Т. 8-927-417-62-73.

*семья из 3-х человек квартиру (р-н Кариева, Нурлатская). Т. 8-927-474-72-76. *семья коттедж, дорого, на длительный срок, предоплата. Т. 8-937-610-48-70.

*организация коттедж (300-400 кв.м) на длительный срок, дорого, предоплата. Т. 8-937-610-48-70.

## САТЫП АЛАМ

*Алгы приводлы «ВАЗ»лар, чит ил машиналары. Кыйммәткә. Т. 8-927-456-00-07.

**12+ "ТНТ-Нурлат" тәкъдим итә**

**13 АПРЕЛЬ**

Музыкаль тапшыру, чуваш телендә.

**15 АПРЕЛЬ**

"Нурлат хәбәрләре", "Татнефть" хәбәрләре.

**17 АПРЕЛЬ**

**"Нурлат хәбәрләре". "Сиңа дигән җырым"**, музыкаль тапшыру

Программалар **19 сәгатьтә** башлана. **14, 16, 18 апрельдә** иртәнге **7дә** кабатлап күрсәтелә.

## РӘХМӘТЕБЕЗ ЧИКСЕЗ

**Чаллы шәһәрендә** яшәгән кадерле сеңлебез **Рәхилә Мәхмүт кызы Кәримованы,** Бикүле авылында яшәгән **Гомәр Мәхмүт улы Кәримовны** соңгы юлга озаткан-да булышкан Бикүле авылы мулласы Шәрифулла бабайга, дин әһелләренә, авыл җирлеге башлыгы Рияз Садыйковка, авылдашларга, туганнарга чиксез рәхмәтебезне белдерәбез. Гаиләләрегезгә югалту кайгылары килмәсен.

**Апасы Минзиннәт, сеңелләре Рабига, Рәкибә.**

*КЫЙММӘТКӘ АВТО САТЫП АЛАМ. Т. 8-937-588-36-46.

*Мөгезле эре терлек, эре терлек тиреләре. Кыйммәткә. Т. 8-927-412-29-99.

*Мөгезле эре терлек, эре терлек тиреләре. Кыйммәткә. Т. 8-927-443-05-43.

*Йорт, документлары белән, 100 меңнән кыйммәт булмасын. Т. 8-960-837-49-31.

*видеомагнитофоны советские, платы, радиодетали. Т. 8-960-822-72-75.

*лом, дорого. Т. 8-9274-222-666.

*КРС, лошадь. Т. 8-927-455-68-10.

*КРС. Т. 8-927-481-30-38.

## АЛЫШТЫРЫЛА

*дом в деревне на квартиру. Т. 8-929-723-06-80.

## ЮГАЛТУЛАР

*утерянное водительское удостоверение тракториста 2 класса, выданное на имя Николая Павловича Савинова, считать недействительным.

*утерянный аттестат А №6997781 об основном (неполном) общем образовании, выданный Вишнеполянской средней общеобразовательной школой Нурлатского района Республики Татарстан от 18.06.1999 г. на имя Галины Владимировны Михайловой, считать недействительным.

**ТЕПЛИЦЫ ОТ ЗАВОДА, ЛЮБЫХ РАЗМЕРОВ. ТЕПЛИЦА 3Х6 - 15800.**

**Т. 8-929-722-29-89.**

**КОЕЛАР БОРАУЛАУ. РАЙОН БУЕНЧА КОЕ БОҖРАЛАРЫН КИТЕРЕП БИРҮ – ТҮЛӘҮСЕЗ. Т. 8-9274-233-978.**

**СВИНИНА** ДЕРЕВЕНСКАЯ, МОЛОДАЯ. 220 РУБ./КГ С ДОСТАВКОЙ. **8-937-616-48-68.**

**АКСУБАЙ ИНКУБАТОРЫ КООБ-500 токымлы бройлерларга заказлар кабул итә.**

**Т.:8-927-671-64-51, 8-843-44-2-78-83.**

**«УЮТ МАСТЕР» компаниясе 100дән артык төстәге теләсә нинди катлаулылыктагы тарттырылма түшәмнәр тәкъдим итә.** 320 сумнан башлап **Т. 8-927-246-52-50.**

**Магазин «Аладдин»**

Матрасы, одеяла, подушки, пледы, спальные комплекты, покрывала, шарфы, платки, тюбетейки, намазлык, полотенца, салфетки, наперники, наволочки, коврики для ванн и прихожих. Клеенки и скатерти. Доступные цены. Работаем за наличный и безналичный расчет.

**г. Нурлат, ул. Гиматдинова, 79. Т.: 8(84345) 2-09-89, 8-967-462-10-03.**

## Искә алыгыз!



14 апрельдә сөекле онычым **Рөстәм Равил улы БАЙБУЛАТОВНЫҢ** якты дөньядан китүенә 5 ел була.

Мин сине беркайчан да онытмам.

Оныгымны белгән барлык кешеләр бу көнне аны изге дога белән искә алса, рәхмәтле булыр идем.

**Әбисе Тәскирә.**

## Кайгы уртаклашабыз

Шәһәр Мәдәният сарае һәм Кама аръягы һәм Нурлат тарихы төбәк музее коллективлары, әнисе **Гыйззелбәнат Хәмитвәли кызы УСМАНОВАНЫҢ** вафат булуы сәбәпле, Фәридә Насыйх кызы Усманованың тирән кайгысын уртаклашалар, хәсрәтле көннәрендә сабырлык телиләр.

